**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 августындагы 3364 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы**
**«Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык,**
**хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган**
**муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген**
**тәэмин итә торган хезмәтләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү**
**турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында**

Үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләр һәм социаль-мәдәни өлкә учреждениеләренең оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр дәрәҗәсен арттыруны тәэмин итү максатыннан **карар бирәм:**

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү турында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 27 июнендәге 2023 номерлы, 2022 елның 26 декабрендәге 4629 номерлы, 2024 елның 26 гыйнварындагы 243 номерлы, 2024 елның 19 июлендәге 3046 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 1 номерлы кушымтасына, 5 нче таблицаны түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«5 нче таблица

| № т/б | Өстәмә матди ярдәм төре | Өстәмә матди ярдәм күләме |
|---|---|---|
| 1 | Бала туу уңаеннан (һәр балага) | Илле мең сум |
| 2 | Баланы уллыкка (кызлыкка) алу уңаеннан (һәр балага) | Илле мең сум |

| № т/б | Өстәмә матди ярдәм төре | Өстәмә матди ярдәм күләме |
|---|---|---|
| 3 | Муниципаль хезмәткәрнең юбилей яисә башка истәлекле датасы уңаеннан:<br>- хатын-кызлар өчен – 50, 55 яшь;<br>- ирләр өчен – 50, 60 яшь;<br>- Татарстан Республикасы территориясендә җирле үзидарә органнарында, муниципаль органнарда, Татарстан Республикасы законы нигезендә җирле хакимият һәм идарә органнарында, муниципаль учреждениеләрдә теләсә нинди вазифаларда 20, 25 ел эш стажы (2005 елга кадәр – Казан шәһәренең тиешле дәүләт органнарында);<br>- 50 ел хезмәт стажы | Биләгән вазифа буенча бер оклад |
| 4 | Хезмәткәрнең каты авыруы уңаеннан | Учреждениенең тиешле комиссиясе (социаль иминият комиссиясе) бәяләмәсе буенча өч айлык хезмәт хакы |
| 5 | Гадәттән тыш хәл нәтиҗәсендә хезмәткәргә китерелгән матди зыянны һәм сәламәтлегенә зыянны каплау максатыннан | Учреждениенең тиешле комиссиясе (социаль иминият комиссиясе) бәяләмәсе буенча өч айлык хезмәт хакы |
| 6 | Хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, ата-анасы вафат булу сәбәпле | Илле мең сум |
| 7 | Хезмәткәрнең ире (хатыны), балалары, ата-анасы каты авыру сәбәпле | Учреждениенең тиешле комиссиясе (социаль иминият комиссиясе) бәяләмәсе буенча егерме мең сум» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**